Мирсәет Яруллин

# ТАҢ КЫЗЫ

*Җырлар*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-1:784
ББК 84 (2Рос=Тат)-5:85.314
Я74

**Яруллин М.З.**

Таң кызы: Җырлар / Мирсәет Яруллин.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.— 147 б.

ISBN 5-298-04012-8

Әлеге җыентыкка күренекле композитор Мирсәет Яруллинның төрле елларда иҗат ителгән җырлары тупланды.

ISBN 5-298-04012-8
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Яруллин М.З., 2006

# ҖЫРЛАР

## **Казан утлары**
*Эльс Гаделев* сүзләре

Җилкендерә ник, канатлар куя
Һәр елны килгән гүзәл бу язлар?
Бергә китерде, сүзләр бирдерде,
Куллар бирдерде кадерле Казан.

Кушымта:
Казан утлары, Казан утлары,
Очрашу, сөю,
Газап утлары —
Онтылмас инде, чыкмас күңелдән
Казан утлары, Казан утлары.

Иңнәрне куйдык иңнәргә дә без,
Каешны будык билләргә дә без,
Күренеп кайттык утлы җилләрдә
Әллә кайдагы илләргә дә без.

Кушымта.

Кояшлар безнең чыкты шушында,
Монда кабынды безнең йолдызлар.
Алда юл ерак әле, егетләр,
Бергә мәңгегә безнең юл, кызлар.

Кушымта.

## **Яшьлек дустыма**
*Илдар Юзеев* сүзләре

Ядкәр язам мин сиңа, дустым,
Китәм ерак якларга.
Яшьлегеңне искә төшерерсең
Бик ямансу чакларда.
Онытма син: гел бергә йөрдек,
Аерылмас дус идек,
Каршыладык күпме таңнарны,
Бергә сөйдек ярларны.
Ядкәр булсын ялкынлы яшьлек,
Эзе калсын елларда.
Онытмаска сүзләр куешып, без
Кузгалабыз юлларга.
Җырла син дә бу моңлы җырны,
Көннәрең булсын нурлы.
Мәңге сакла дуслык сүзләрең,
Җирдә калсын эзләрең.

**Урманнарга килдем**
*Илдар Юзеев* сүзләре

Урманнарга килдем, берьялгызым
Кошлар белән йөрим сөйләшеп.
Сагнуларым сыймый йөрәгемә,
Коштан кошка йөрим өләшеп.

Урманнарга килдем, табалмадым,
Кычкырсам да исмең эндәшеп.
Серләшергә янда дусларым юк,
Кошлар белән йөрим серләшеп.

Урманнарга килдем, ташып чыккан
Тойгыларым белән көрәшеп.
Сагнуларым сыймый йөрәгемә,
Коштан кошка йөрим өләшеп.

**Күпме күзләр күреп онытылган...**
*Шәүкәт Галиев* сүзләре

Күпме күзләр күреп онытылган,
Күпме йөзләр чыккан исемнән;
Күпме сүзләр киткән хәтеремнән,
Ә син һаман, һаман исемдә.

Ничә тапкыр гүзәлләрне күреп,
Мин минутлык хискә исердем.
Айнадым да, сөенеп туялмыйча,
Тагын сине искә төшердем.

Йөрәгемне, ахры, тутыргансың,
Башкаларга анда урын юк.
Күңелемдә синнән бүтәннәргә
«Сөям» дигән назлы җырым юк.

**Сагынырмын, Мөслим!**
*Марс Шабаев* сүзләре

Бала кошлар оя ташлый,
Үскәч тә канатлары.
Китәм — иркен урамнарың
Озатып карап калыр.

Кушымта:
Их, Мөслим, инде нишлим? —
Сагынырмын ич мин.
Яхшылыкларыңны, Мөслим,
Оныталмам һич мин!

Әнкәм булып, яулык болгап,
Хәерле юллар телә.

Тынгы белмәс улларыңа
Айрылу көне килә.

Кушымта.

Яшькелт Ыкка һәрвакытта
Ашкына акчарлаклар.
Мин дә сиңа ашкынырмын —
Онтылмый туган яклар.

Кушымта.

Ашкынырмын, талпынырмын,
Кайтырмын, газиз җирем.
Син мине назлап үстердең,
Син миңа канат бирдең.
Кушымта.

**Татарстан**
*Разил Вәлиев* сүзләре

Яшьлекнең таңында мин күпме
Хыялый сарайлар кормадым!
Хыялны канатлы кош итте,
Туган җир, тик синең җырларың.

Кушымта:
Без — дусларга ак күгәрчен,
Дошманнарга — арыслан.
Безгә шундый иман бирдең,
Көч бирдең, Татарстан.

Йөрәктә син булган чагында,
Ялгыз да, ятим дә булмамын!
Мәңгелек көч алам Иделдән,
Җаныма коя күк Чулманың.

Кушымта.

Безгә бит бергәләп кичәсе
Дөньяның давыллы елларын...
Тик бәхет ягына илтсеннәр,
Илтсеннәр Ватаным юллары!

Кушымта.

**Нефтьчеләр**
*Ренат Харис* сүзләре

Нур өстенә нурлар өстәп,
Илдә кара алтын чыга.
Әлмәт, Баку, Төмән, Сибай,

Мангышлактан алтынчылар.

Кушымта:

Җир шарының үзәгенә кадәр
Юллар салдылар алар.
Девон көчен кояш яктысына
Ялгый алдылар алар.
Саф күңелле осталар.

Ватанның абруе зурдан,
Барлык илләр исәпләшә.
Кара алтынга да бәйле
Җирдә сугышларсыз яшәү!

Кушымта.

Мең рәхмәткә лаеклылар
Кара алтын табучылар.
Ил бәхете китабына
Сүнмәс сүзләр язучылар.

Кушымта.

**Урман-кырлар**
*Әнисә Ибраһимова* сүзләре

Урман-кырлар, агыла-агыла җырлар,
Бәхет алып килә безгә еллар.
Аяз күктән сибелә нурлар,
Алларымда якты юллар.
Нигә тынмый йөрәктә моңнар?
Идел генә шулай нык дулар,
Айкалганда шаулы дулкыннар.

Урман-кырлар, уртак булсын серләр,
Зәңгәр күзле шаян бер кыз бар.
Аяз күкне бергә күзләү,
Таң йолдызыбызны эзләү...
Күңелем тулы шундый хыяллар.
Йөрәгемдә кайнар сөю бар,
Аңларсыңмы мине, гүзәл яр?

**Бәхет белән тулган көн**
*Разил Вәлиев* сүзләре

Таңда туган кояш баласы син,
Таң нурлары булып иңгәнсең...
Таң шикелле балкып елмаясың,
Кайгыларны куып көләсең.

Кушымта:

Җырлата да туган көн,
Елата да туган көн.

Бөтен дөнья шатлык белән,
Бәхет белән тулган көн.

Ага еллар ярсу елга сыман.
Син каршыга йөзеп киләсең.
Җил-давыллар күпме сынагандыр
Дәрьядагы язмыш көймәсен.

Кушымта.

Таңда туган таң баласы бит син...
Таңга кадәр бергә җырлашыйк.
Мәңгелеккә җиргә килмәсәк тә,
Бу дөньяга мәңге без гашыйк.

Кушымта:

Җырлата да туган көн,
Елата да туган көн.
Бөтен дөнья сагыш белән,
Бәхет белән тулган көн.

**Аланнар**

*Гәрәй Рәхим* сүзләре

Урманнарга килеп керүгә,
Дәшеп ала мине аланнар.
Без танышкан ерак бер җәйдә,
Икәү тезгән алсу мәрҗәндәй,
Тәлгәшләрдә яна баланнар.

Бәлки, син дә монда килгәнсең,
Аланнарга сәлам биргәнсең?
Чәчәкләрдә әнә чык яна,
Үләннәрдә эзләр өр-яңа —
Мин киләсен син дә белгәнсең.

Җәйләр инде узып баралар,
Ямансулый, ахры, аланнар.
Тагын бер кил, дустым, бирегә,
Мәңгелек ут булып сөюгә
Аланнарда яна баланнар.

**Бөрлегән**

*Муса Җәлил* сүзләре

Җыеп кырдан бөрлегән,
Килгән иркәм, бер генәм.
Ә мин аңа сөюемне
Белдерәлми тилмерәм.

Кунак итә гөл генәм,
Мине бөрлегән белән.
Белми ләкин — иреннәре

Иң өлгергән бөрлегән.

## Су буенда кыяк үлән

*Клара Булатова* сүзләре

Су буенда кыяк үлән
Язын булмый торгандыр.
Бәлки, ул да таңнар белән
Мине уйлый торгандыр.

Су буенда кыяк үлән
Язын булмый торгандыр.
Бәлки, ул да минем кебек
Янып-көя торгандыр.

Су буенда кыяк үлән
Чабып алса, ни була.
Уйлап йөргәч, сөям дигән
Хәбәр салса, ни була.

## Җирдә бер кояш

*Ренат Харис* сүзләре

Йөз куя дөнья
Кояш нурына —
Әйдәгез җырлыйк
Кояш турында:
Кояш — безнең йөздә,
Кояш — безнең күздә,
Кояш — безнең сүздә, дуслар!

Һава сафлыгы
Яшьләр кулында —
Әйдәгез җырлыйк
Һава турында:
Һава шул ук миңа,
Һава шул ук сиңа,
Һава шул ук безгә, дуслар!

Җир гүзәллеге
Бердәм булуда —
Әйдәгез җырлыйк
Без Җир турында:
Җирдә бер үк кояш,
Җирдә бер үк һава,
Җирдә бер үк яшьләр, дуслар!

Хәзер тын калыйк
Шушы урында —
Тынлык сөйләсен
Теләк турында:
Синең теләк — дуслык,
Минем теләк — дуслык,
Безнең терәк — дуслык, яшьләр!

**Гөлчәчәк**
*Марс Шабаев* сүзләре

Күрәсеңме яңгыр теләп
Алсуланган гөлчәчәкне:
Мин дә шулай сине генә
Көттем, көтәм, көтәчәкмен.

Чәчәк сизә алсу битен
Тамчы төшеп үбәчәген;
Мин дә шулай сине генә
Сөйдем, сөям, сөячәкмен.

**Кара күзләр, кара керфекләр**
*Мәхмүт Хөсәен* сүзләре

Мин яраткан күзләр, керфекләр
Янып торган шомырт кебекләр.
Ах, ник күрдем сезне юлымда,
Кара күзләр, кара керфекләр.

Гыйшык көчле була кешедә,
Тирән була, сөйсәң, өметләр.
Яздырмагыз мине акылдан,
Кара күзләр, кара керфекләр.

Күнче кызлар, күнче егетләр:
«Оныт, оныт»,— диеп үгетләр.
Юк, онытмам, сез гел күңелдә,
Кара күзләр, кара керфекләр.

**Урман җырлый**
*Сөббух Рафиков* сүзләре

Язгы урман нурга тулган,
Күз алмыйм юлларыннан.
Энҗе нурлары чагыла
Язгы кар суларыннан.

Берсен берсе узып сайрый
Канатлы дус — җырчылар.
Уйга калып җыр тыңлыйлар
Яшәргәндәй чыршылар.

Урман җырлый. Төз наратлар
Унсигездә кебекләр.
Кыңгыраулы гармун уйнап
Гүя уза егетләр.

**Акчарлаклар сине сагына**
*Рафис Корбан* сүзләре

Акчарлаклар оча Иж буйларын иңләп,
Алар очып үтмәс ара юк.
Акчарлаклар кайта язлар саен Рыска,
Безнең генә кайтыр чара юк.

Акчарлаклар кебек очып кайтыр идек,
Юк шул инде кайтыр җиребез.
Юк шул инде, җирдә юк Рыс дигән авыл,
Туган җирсез ятим инде без.

Акчарлаклар да бит, беркөн сине җуеп,
Иж өстендә үксеп кычкырды.
Ташкын сулар алды кочагына сине,
Туган авылым Рыс, хуш инде.

Сагыш булып кына калдың күңелләрдә,
Су төбендә калдың күмелеп.
Туган авылым Рыс, үскән авылыбыз,
Сине сагына, эзли күңелем.

**Син булганга**
*Ләбиб Айтуганов* сүзләре

Ал таңнарны каршы алам,
Саф нурларга карап сокланам.
Йомшак чиртеп күңел кылын,
Тирбәлә җыр — талгын моң тулы.
Ашкына йөрәк,
Талпына йөрәк,
Елмаеп керәм мин, иркәм, һәр көнгә:
Тәрәзәң ачып,
Кояш кебек балкып
Елмайганга, сөеклем, син дә.

Үтә алам биек тауны,
Кичә алам мин бозлы суны.
Юлсыз җирдә сукмак салам,
Яктылыкка, алга гел барам.
Хисләрем көчле,
Давыллар төсле,
Бирешмәс алар һич давылга, җилгә:
Уйларым белеп,
Йөрәккә дәрт биреп
Атлаганга, сөеклем, син дә.

Бу тормышны мин яратам,
Гел шатлыклы гына карашым.
Юлларым уң, кая барсам,
Хисем көч бирә, әгәр талсам.
Иң-иң дәртле мин,
Иң бәхетле мин.

Үзем мәңге гашыйк чәчәкле бу җирдә:
Кошлардай сайрап, уртак юллар сайлап
Яшәгәнгә, сөеклем, син дә.

**Янып көясем килә**
*Шәүкәт Галиев сүзләре*

Туйдырды пыскып яшәүләр,
Янып көясем килә,
Янып көясем килә лә,
Шашып сөясем килә!

Сөеп, сөенеп үзеннән
Күз алалмаслык булсын,
Ияреп кителсен артыннан,
Һич калалмаслык булсын!

Сагынылсын, саргаелсын,
Ашау үтмәслек булсын,
Мәхәббәтем аңлатырга
Сүзләр җитмәслек булсын!

Ярым кем булырын белмим,
Мин әле ялгыз йөрим.
Йә, кайсыгыз сөйдерала,
Яндыра, көйдерала?

**Карасам гомер юлыма...**
*Гәрәй Рәхим* сүзләре

Болыннарга чыгып сокландым,
Көмеш диеп таңнар чыгына.
Ә карасам, чәчәк күзендә
Көмеш кебек яна су гына.
Карасам мин таңнар чыгына,
Янып тора анда су гына.

Чишмәләрдә челтер-челтер дип
Ага дигән идем җыр гына.
Ә тыңласам, улак эчендә
Җырлап ага икән су гына.
Улакларда дисәм җыр гына,
Җырлап ага икән су гына.

Нинди гүзәл, матур син диеп,
Сокландым мин гомер юлыма.
Ә карасам гомер юлыма,
Агып ята анда моң гына.
Карасам мин гомер юлыма,
Агып ята анда моң гына.

**Серле чәчәк**

*Илдар Юзеев* сүзләре

Исмеңне дә белмим,
Төсеңне дә белмим,
Хыялымда гына дәшәмен,
Кичен күзен йомып,
Иртән керфекләрен
Ача торган серле чәчәгем!

Язлар каршы алып,
Күпме еллар сине
Табу уе белән яшәдем,
Кичен күзен йомып,
Иртән керфекләрен
Ача торган серле чәчәгем!

Бер иртәне эзләп
Табармын да сине,
Исмең белән сөеп дәшәрмен.
Юк, мин өзмәм сине,
Җилләр тидермичә,
Гомрем буе назлап яшәрмен,
Кичен күзен йомып,
Иртән керфекләрен
Ача торган серле чәчәгем!

**Зирекле күл**
*Абдулла Сәләхетдинов* сүзләре

Тик бер генә тапкыр килсәң дә,
Тик бер генә тапкыр күрсәң дә,
Урнашыр да күңлең түренә,
Онтылмаслык булыр гомергә.

Кушымта:
Зөянең тын агышы,
Зирекле күл камышы.
Тормышларның хушлыгы —
Авылдашлар дуслыгы.

Зөя суын эчкән сылулар —
Зифа талдан зифа буйлылар.
Күзен сирпеп кенә карасын —
Гомер буе дөрләп янарсың.

Кушымта.

Зөя буе, кырлар — икмәкле,
Аксакаллар сүзе хикмәтле:
Туган авыл илдә бер булыр,
Аның кадрен асыл ир белер.

Кушымта.

**Игенче шатлыгы**
*Юныс Адаш* сүзләре

Җәй кояшы, юмартланып,
Нурларын сибә җиргә.
Сәламләп хезмәт иртәсен
Башаклар шаулый җилдә.

Кушымта:
Дулкынлана диңгез кебек
Киң иген кыры.
Җырлап килә комбайнында
Кырлар батыры.

Җәен-кышын җиң сызганып,
Солдатча буып билен,
Яулады ул илгә уңыш,
Кайрылып уңды иген.

Кушымта:
Хөрмәтләде игенчене
Изге Җир-ана.
Гәрәбәдәй тук бөртекләр
Үстерде аңа.

Ипләп кырны, җай тирбәлеп
Йөзә дә йөзә кораб.
Сокланып туймый игенче,
Шат дулкыннарга карап.

Кушымта:
Куана ул: мул тормышта
Яшәр кешеләр.
Тау-тау өелә ындырда
Алтын көшелләр.

**Кызлар җырлый**
*Разил Вәлиев* сүзләре

Кызлар җырлый, кызлар җырлый,
Кызлар җыры — сагышлы.
Кызлар җырына җыелган
Язмышларның ялгышы.

Кушымта:
Кызлар җырын тыңлаганда,
Җан җылылары алам.
Җир үзенең сөенечен,
Бәхетен һәм көенечен

Кызлар җырына салган.

Кызлар җырлый, кызлар җырлый,
Кызлар җыры — канатлы.
Кызлар җыры күңелдәге
Сагышларны таратты.

Кушымта.

Кызлар җырлый, кызлар җырлый,
Кызлар җыры — кояшлы.
Кызлар җырында — шатлыгым,
Сагышларымның башы.

Кушымта.

**Рәмзия**
*Рәшит Шиһапов* сүзләре

Батист күлмәгеңне киеп,
Урамнардан узасың;
Бер елмаеп карыйсың да
Үзәгемне өзәсең.
Ай, җаныем, Рәмзиям,
Сандугачым син, диям.
Яшьлегемнең таң йолдызы —
Синең утыңда көям.

Ай нурын сибә йөзеңә —
Син суларга барасың;
Җиргә түгел, гүя минем
Йөрәгемә басасың...
Ай, җаныем, Рәмзиям,
Зәңгәр синең күзләрең!
Кайчан әйтерсең икән соң
«Сөям» дигән сүзләрең!

**Татарстаным минем**
*Ренат Харис* сүзләре

Син безне тудырдың, үстердең,
Тик сиңа бурычлы мәңге без.
Юк бит ул тагын бер синдәй җир:
Язың — яз,
Җәең — җәй,
Көзең — көз!
Язың — яз,
Җәең — җәй,
Көзең — көз!

Көч бирдең, дәрт бирдең, рух бирдең,
Улларың, кызларың баһадир.

Сокланмый мөмкинме соң сиңа:
Суың — су,
Күгең — күк,
Җирең — җир!
Суың — су,
Күгең — күк,
Җирең — җир!

Яуларда, хезмәттә, сәнгатьтә
Исемең акладык, Татарстан.
Син безне күтәрдең, без — сине!
Язың — яз,
Җирең — җир,
Даның — дан!
Язың — яз,
Җирең — җир,
Даның — дан!

**Яшь төзүче**
*Ләбиб Айтуганов* сүзләре

Киң юллар сузыла еракка —
Илнең төрле ягына.
Сөеп каршылыйлар безне,
Барсак та кая гына.

Кушымта:
Яшь төзүче,
Яшь төзүче,
Ашкынулы теләгең.
Киң далада зур калалар —
Туган илгә бүләгең.

Киң юллар сузыла еракка —
Яңа төзелешләргә.
Йөрәктә яшьлек ялкыны
Чакыра кыю эшләргә.

Кушымта.

Киң юллар сузыла еракка —
Ул юллар олы, туры.
Яшьлегебезгә тиң булып
Яңгырый хезмәт җыры.
Кушымта.

**Яшьлегем**
*Кави Латыйп* сүзләре

Яшьлегем, утлы яшьлегем,
Чыныктың окопларда;

Җир тетрәтеп, күк күкрәтеп
Йөрдең син походларда.

Яшьлегем, дәртле яшьлегем,
Талмадың, арымадың;
Тайгаларда, далаларда
Җыр булып яңгырадың.

Яшьлегем, сүнмәс яшьлегем,
Ялкыннан, уттан көчле;
Балкы җирдә син, яшьлегем,
Космоста йолдыз төсле.

**Син керәсең йөрәгемә**
*Әхмәт Ерикәй* сүзләре

Бакчаларда чәчәкләнә
Чияләр матур булып.
Син керәсең йөрәгемә
Чәчәк булып, җыр булып.

Гөлгә тиңләсәм дә сине,
Син гөлдән матурырак
Гөл кулымда, син уемда,
Син миңа якынырак

# БАЛАЛАР ӨЧЕН ҖЫРЛАР

**Табигать балалары**
*Разил Вәлиев* сүзләре

Җилкәдә — поход биштәре,
Күңелдә — серле уйлар.
Безнең хыял, шатлык эзләп,
Дөньяны мең кат буйлар.

Без — табигать балалары,
Безнең бәхетле чаклар.
Җир өстеннән төнне куып,
Дөрләп янар учаклар.

Каршылар безне урманнар,
Озатып калыр кырлар.
Юлдаш булыр мәктәпләрдә
Өйрәнгән дәртле җырлар.

**Күпме сер көтә безне**
Эзтабарлар җыры
*Мәхмүт Хөсәен* сүзләре

Без табабыз сугышларда
Хәбәрсез югалганны.
Зур җиңүгә утлар аша
Данлы юл салганнарны.

Кушымта:
Яңаны, кызыклыны
Табарга без осталар.
Без белмибез тынгыны,
Без — ялкынлы эзтабар!

Безнең колак күп ишетә,
Күп күрә безнең күзләр.
Могҗизалар дөньясына
Сузыла безнең эзләр.

Кушымта.

Каһарманнарга мәхәббәт
Гел алга илтә безне.
Күпме легендар язмышлар,
Күпме сер көтә безне.
Кушымта.

**Мәктәпкә барасы бар**
*Гәрәй Рәхим* сүзләре

Туйганчы уйнар идем дә,
Минем шул вакытым тар.
Иртәгә бишле алырга
Мәктәпкә барасы бар.

Әтәчебез сизәр микән —
Бик иртә торасы бар.
Сез дә озак йокламагыз —
Мәктәпкә барасы бар.

Киләчәктә Туган илдә
Зур юллар саласы бар.
Ә хәзергә соңламыйча
Мәктәпкә барасы бар.

**Соңгы звонок**
*Энҗе Мөэминова* сүзләре

Көмеш тәңкә чыңлавыдай
Нәфис тавышың
Хәтерләтә таудан төшкән
Чишмә тавышын.

Кушымта:
Соңгы звонок
Озата юлга,
Соңгы звонок
Чакыра алга.

Якын дустан аерылуны
Сизгән шикелле,
Моңландыра синең тавышың
Бүген күңелне.

Кушымта.

Ерак юлга озатучы
Якын дус кебек,
Җылы хисләр уятасың
Күңел җилкетеп.
Кушымта.

**Җыеныгыз ерак юлга**
*Габделхәй Сабитов* сүзләре

Белем кирәк ерак юлга,
Белемле меңне ега.
Диңгезләрнең төбен күзләп,
Атлантида илен эзләп
Җир улы сәфәр чыга.

Кушымта:

Быргылар хәбәр итә:
— Безгә дә,
Безгә дә,
Безгә дә вакыт җитә.

Чүлдә бакча ясый кеше,
Таулар аша юл яра.
Тайфун белән ярышырга,
Вулкан белән алышырга
Кыюлар яуга бара.

Кушымта.

Җыеныгыз ерак юлга,
Йолдыз җилләре исә.
Җилкәннәрдә җил уйнатып,
Киек Каз Юлы буйлатып
Кораблар галәм кичә.

Кушымта.

# СПЕКТАКЛЬЛӘР ӨЧЕН ЯЗЫЛГАН ҖЫРЛАР

**Кара урман безнең өебез...**

«Азат» спектакленнән коллар җыры
*Туфан Миңнуллин* сүзләре

Кара урман безнең өебез иде,
Чикләвекләр безнең сыебыз иде.
Явыз дию килде урманга,
Әйләндерде безне колларга.

Газап белән үтә көнебез,
Интегәбез дию кулында.
Тик бер өмет белән яшибез,
Хыялланып ирек турында.

**Кояш нурлары**

«Азат» спектакленнән
*Марс Шабаев* сүзләре

Алтын кояш көлә, нурлар уйный,
Шаяралар алар, күрәсезме?
Йөгерсәң дә җитез җилләр кебек,
Тотып булмый, нурлар, ах, сезне!

Кушымта:

Әй, кояш, син шаярма, шаярма,
Күркә кебек кабарма.
Әйдә, аяк бас, катырак бас.
Нурлар бездән кача алмас,
Арсаң да, дус, син артка карама.

Урман шаулап тора, кошлар җырлый,
Алар безне һаман алга дәшә.
Кояш нурларында каралмаган
Ак каеннар бездән көнләшә.

Кушымта.

Походларда йөреп, эштә янып,
Чуен кебек булсын, дус, тәннәрең.
Тир тамудан куркып качып ятсаң,
Нурсыз үтәр синең көннәрең.
Кушымта.

**Канкай углы Бәхтияр**

«Канкай углы Бәхтияр» спектакленнән
*Илдар Юзеев* сүзләре

Тып-тып тояк тавышын
Тыңлап үскән баладыр;
Урал тауның сагышын
Җырлап үскән баладыр.
Акбүз атта барадыр
Канкай углы Бәхтияр.

Юллар бергә килгәнгә,
Ике батыр дус булган.
«Уң кулым — син»,— дигәнгә
Күңелләре хуш булган.
Пугачауга кушылган
Канкай углы Бәхтияр.

Тып-тып тояк тавышын
Челдерәтеп барадыр...
Морадына җитмичә,
Тынмый торган баладыр.
Сынмый торган баладыр
Канкай углы Бәхтияр.

**Фәүзия җыры**

«Янар чәчәк» спектакленнән
*Илдар Юзеев* сүзләре

Нинди матур озын юлга чыктык,
Янар чәчәк иде юл башы.
Чәчәк сулган, синең йөрәгеңә
Ниләр булган, яшьлек юлдашым?

Яшьлегемне искә төшергәндәй,
Дәфтәр битен кичке җил ача.
Еракларда калган тавышыңны
Җил дә алып килми, ичмаса.

**Лира җыры**

«Янар чәчәк» спектакленнән
*Илдар Юзеев* сүзләре

Карт наратлар сорый: «Төн йокламый,
Ни уйлыйсың болай, сеңелем?»
Мин үзем дә белмим: нәрсә булды,
Ниләр уйлый минем күңелем?

Карт наратлар әйтә: «Җидегән йолдыз
Сүнәр инде, йокла, сеңелем».
Минем өчен яңа йолдыз калкыр,
Юк, сүрелмәс минем күңелем.

Карт наратлар тына: «Йокла инде,
Хәерле төн сиңа, сеңелем».
Ашкынулар, шикләнүләр белән
Үз йолдызын көтә күңелем.

## Килерсеңме, егеткәй?

«Тынгысыз төн» спектакленнән кызлар вальсы
*Газиз Мөхәммәтшин* сүзләре

Алмагачка чыклар төшкән,
Аны сандугачлар эчкән —
Күрәсеңме, егеткәй?
Минем күңлем сиңа төште,
Исемнән чыкмыйсың һич тә —
Сизәсеңме, сизәсеңме,
сизәсеңме, егеткәй?

Чәчәк аткан алмагачлар,
Чүт-чүт сайрый сандугачлар —
Тыңладыңмы, егеткәй?
Ул да тыңлый торгандыр дип,
Мине уйлый торгандыр дип,
Уйладыңмы, уйладыңмы,
уйладыңмы, егеткәй?

Яз — гашыйклар үбешкән чак,
Егет-кызлар күрешкән чак —
Беләсеңме, егеткәй?
Челтер-челтер чишмә ага,
Чибәр кызлар суга бара —
Килерсеңме, килерсеңме,
килерсеңме, егеткәй?

## Алсуланып таңнар атканда

«Тынгысыз төн» спектакленнән
*Газиз Мөхәммәтшин* сүзләре

Алсуланып таңнар атканда,
Дулкыннарның таушын тыңладым;
Дулкыннарның таушын тыңладым да
Сиңа атап җырлар җырладым.

Сине сагнып җырлар җырладым,
Синдә генә минем уйларым;
Сагына микән иркәм мине, дип,
Көмеш дулкыннардан сорадым.

Ак дулкыннар шаулап килделәр,
Болай диеп җавап бирделәр:
— Моңайма син, сеңлем, уйланма,

Сагына иркәң сине,— диделәр.

## Таң кызы җыры

«Соңгы төн» спектакленнән
*Илдар Юзеев* сүзләре

Таң җилләре чәчләремне
Уйнап сүтәләр.
Тын дулкыннар йөрәгемне
Назлап үтәләр.

Белгән сыман уйларымны,
Җилләр исәләр.
Алар минем җилкәнемне
Сиңа илтәләр.

Серле көчләр җилкәнемне
Сиңа илтәләр.
Төнбоеклар сөенечле
Таңны көтәләр.

Җылы нурлар төнбоекның
Яшен сөртәләр.
Сөю бәхетенә тусын
Таңнар, иртәләр.

## Эчтәлек


**Җырлар**

Казан утлары. *Э.Гаделев* сүзләре
Яшьлек дустыма. *И.Юзеев* сүзләре
Урманнарга килдем. *И.Юзеев* сүзләре
Күпме күзләр күреп онытылган... *Ш.Галиев* сүзләре
Сагынырмын, Мөслим! *М.Шабаев* сүзләре
Татарстан. *Р.Вәлиев* сүзләре
Нефтьчеләр. *Р.Харис* сүзләре
Урман-кырлар. *Ә.Ибраһимова* сүзләре
Бәхет белән тулган көн. *Р.Вәлиев* сүзләре
Аланнар. *Г.Рәхим* сүзләре
Бөрлегән. *М.Җәлил* сүзләре
Су буенда кыяк үлән. *К.Булатова* сүзләре
Җирдә бер кояш. *Р.Харис* сүзләре
Гөлчәчәк. *М.Шабаев* сүзләре
Кара күзләр, кара керфекләр. *М.Хөсәен* сүзләре
Урман җырлый. *С.Рафиков* сүзләре
Акчарлаклар сине сагына. *Р .Корбан* сүзләре
Син булганга. *Л.Айтуганов* сүзләре
Янып көясем килә. *Ш.Галиев* сүзләре
Карасам гомер юлыма... *Г.Рәхим* сүзләре
Серле чәчәк. *И.Юзеев* сүзләре
Зирекле күл. *А.Сәләхетдинов* сүзләре
Игенче шатлыгы. *Ю.Адаш* сүзләре
Кызлар җырлый. *Р.Вәлиев* сүзләре
Рәмзия. *Р.Шиһапов* сүзләре
Татарстаным минем. *Р.Харис* сүзләре
Яшь төзүче. *Л.Айтуганов* сүзләре
Яшьлегем. *К.Латыйп* сүзләре
Син керәсең йөрәгемә. *Ә.Ерикәй* сүзләре

**Балалар өчен җырлар**

Табигать балалары. *Р.Вәлиев* сүзләре
Күпме сер көтә безне. *М.Хөсәен* сүзләре
Мәктәпкә барасы бар. *Г.Рәхим* сүзләре
Соңгы звонок. *Э.Мөэминова* сүзләре
Җыеныгыз ерак юлга. *Г.Сабитов* сүзләре

**Спектакльләр өчен язылган җырлар**

Кара урман безнең өебез... «Азат» спектакленнән коллар җыры. *Т.Миңнуллин* сүзләре
Кояш нурлары. «Азат» спектакленнән. *М.Шабаев* сүзләре

Канкай углы Бәхтияр. «Канкай углы Бәхтияр» спектакленнән. *И.Юзеев* сүзләре

Фәүзия җыры. «Янар чәчәк» спектакленнән. *И.Юзеев* сүзләре

Лира җыры. «Янар чәчәк» спектакленнән. *И.Юзеев* сүзләре

Килерсеңме, егеткәй? «Тынгысыз төн» спектакленнән кызлар вальсы.

*Г.Мөхәммәтшин* сүзләре

Алсуланып таңнар атканда. «Тынгысыз төн» спектакленнән. *Г.Мөхәммәтшин* сүзләре
Таң кызы җыры. «Соңгы төн» спектакленнән. *И.Юзеев* сүзләре

Нотное издание

***Яруллин*** *Мирсаид Загидуллович*

ДЕВУШКА ЗАРИ
Песни

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Ноталы басма

***Яруллин*** *Мирсәет Заһидуллович*

ТАҢ КЫЗЫ
Җырлар

Музыкаль мөхәррире *И. И. Байтирәк*
Мөхәррире *В. Р. Камалиева*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Ноталарны компьютерда җыючы *И. И. Байтирәк*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.12.2006. Форматы 60х90 1/8.
Офсет кәгазе. Офсет басма. Басма табагы 18,0. Шартлы буяу-оттиск 19,0.
Нәшер-хисап табагы 17,82.
Тиражы 2000 экз. Заказ З-1061.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru   e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.